**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН СОВЕТ ПСЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МЕНДЕЛЕЕВ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ПЕСӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

---

**Р Е Ш Е Н И Е** **К А Р А Р**

**3 июль 2020 ел** **№ 150**

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районының
Песәй авыл җирлегендә
муниципаль хезмәт турында
нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2007 елның 2 мартындагы "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 25-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексы белән, Менделеевск муниципаль районының Песәй авыл җирлеге Уставы белән Менделеевск муниципаль районының Песәй авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. 2020 елның 25 мартыннан 140 нчы номерлы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Песәй авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2 кушымтасындагы 18 пунктының 1 абзацын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18. Муниципаль хезмәткәр вазыйфасында киметелгән яки аның ризалыгыннан башка муниципаль хезмәт урынына күчерү мөмкинлеге булмаган очракта, эшкә алучы (эш бирүче) вәкиле, аттестация нәтиҗәләре белән расланган квалификация җитәрлек булмау сәбәпле, аттестация узганнан соң, аны муниципаль хезмәттән азат итәргә мөмкин. Күрсәтелгән вакыт узганнан соң муниципаль хезмәткәрне эштән азат итү яки аны әлеге аттестация нәтиҗәләре буенча вазыйфада киметү рөхсәт ителми.»

1.2. 1 нче кушымтаның 12 статьясындагы 1 пунктының 2 пунктчасын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) коммерция яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашу, түбәндәге очраклардан тыш:

а) сәяси партия белән идарә итүдә, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы тарафыннан түләүсез нигездә катнашу, башка иҗтимагый оешма, торак, гараж кооперативлары съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтендә катнашу;

б) коммерциягә карамаган оешма идарәсендә (сәяси партия идарәсендә, һөнәри берлек органында, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының

сайланулы органы тарафыннан катнашудан, башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, күчемсез милек милекчеләре ширкәтләренең съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында катнашудан тыш) катнашу, яллаучы вәкиленең Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән тәртиптә алынган рөхсәте белән;
в) Россия Федерациясе субъекты муниципаль берәмлекләре советында, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә күрсәтү;
г) муниципаль берәмлек муниципаль берәмлекне гамәлгә куючы (катнашучы) муниципаль берәмлек булган оешманың идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә оешманы гамәлгә куючы (акционер) тарафыннан оешманы гамәлгә куючының вәкаләтләрен муниципаль берәмлек исеменнән гамәлгә ашыру тәртибен йә муниципаль милектәге акцияләр (устав капиталындагы өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә түләүсез нигездә тапшыру;

1.3. 1 нче кушымтаның 12 статьясындагы 1 пунктына түбәндәге редакциядә 2.1 пунктчасын өстәргә:
2.1) эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шәхсән яки ышанычлы затлар аша шөгыльләнергә;»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendelevsk.tatarstan.ru "Песәй авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Песәй авыл җирлеге
Советы Рәисе В.И. Мөхәммәтгалеев